ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 1203 2016 елның 21 июле

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә (оешмаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү (балалар бакчалары)» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 15 июлендә кабул ителгән 924 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы бер оешмадан укучыларны тиешле дәрәҗәдәге һәм юнәлештәге белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы башка оешмаларга күчерү тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2015 елның 28 декабрендәге 1527 номерлы боерыгы нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә (оешмаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү (балалар бакчалары)» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 15 июлендәге 924 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. «Стандарт таләпләре эчтәлеге» 2.14 пунктын түбәндәге эчтәлек белән тулыландырырга:

«муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм урыннарда гамәлгә ашырыла.

Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керә алуы тәэмин ителә (биналарга уңайлы керү-чыгу һәм алар чикләрендә күчеп йөрү).

Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла».

1.2. 3.7.1 пунктны түбәндәге эчтәлек белән тулыландырырга:

«Баланы күчерү уку елы чорына (вакытына) бәйле түгел.

Баланы эти-әнисе (законлы вәкилләре) инициативасы буенча күчергән очракта, баланың ата-анасы (законлы вәкилләре):

- кабул итүче оешманы сайлауны гамәлгә ашыралар;
- «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» ДБУнең Түбән Кама филиалына (алга таба – КФҮ) баланың тиешле яшь категориясе һәм кирәкле юнәлештәге төркеме, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән (алга таба-Интернет) файдаланып,

буш урыннар булу турында сорату белән мөрәҗәгать итәләр. Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе мөдирләре (алга таба – балалар бакчасы) ел дәвамында мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренең рәсми сайтында буш урыннар булуы турында актуаль мәгълүмат урнаштыралар.

- баланы күчерү турында гариза белән КФҮкә мөрәҗәгать итәләр.

Баланың күчерү гаризасында ата-ана (законлы вәкилләре) күрсәтә:

а) баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда);

б) туу датасы;

в) туу турында таныклык;

г) кабул итүче оешманың исеме;

д) яшәү адресы;

е) баланың СНИЛСы.

Баланы элеккеге оешмадан чыгару автомат рәвештә башкарыла. Баланы мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенә кабул итү турындагы беркетмә нигезендә, элеккеге оешма, өч көн эчендә, кабул итүче оешманы күрсәтеп, тәрбияләнүчене күчерү тәртибендә чыгару турында күрсәтмә акты чыгара.

Элеккеге оешма ата-аналарга (законлы вәкилләренә) баланың шәхси эшен (алга таба - шәхси эш) бирә.

Элеккеге булмаган оешмага күчерү белән бәйле, баланы кабул итүче оешмага кабул итү өчен нигез буларак, башка документларны бирүне таләп итү рөхсәт ителми.

Шәхси эш ата-аналар (законлы вәкилләр) тарафыннан баланы кабул итүче оешмага элекке оешмадан күчерү тәртибендә әлеге оешмага кабул итү турында гариза белән бергә һәм бала ата-анасының (законлы вәкилнең) шәхесен таныклаучы документның төп нөсхәсен күрсәтеп тапшырыла.

Гаризаны һәм шәхси эшне кабул иткәннән соң, кабул итүче оешма баланың ата – аналары (законлы вәкилләре) белән мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем алу турында шартнамә төзи һәм шартнамә төзегәннән соң өч эш көне эчендә баланы күчерү тәртибендә кабул итү турында күрсәтмә акт чыгара.

Баланы кабул иткәндә кабул итүче оешма баланы күчерү тәртибендә кабул итү турында күрсәтмә акт чыккан көннән ике эш көне эчендә баланы кабул итүче оешмага кабул итү турындагы күрсәтмә актның номеры һәм датасы турында элеккеге оешмага язмача хәбәр итә.

1.3. 3.7.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Оешма бетерелгән яки эшчәнлеге туктатылган очракта, тәрбияләнүчеләр башка оешмаларга чираттан тыш тәртиптә күчерелә.

Элеккеге оешманың эшчәнлеген туктату турында карар кабул иткәндә, гамәлгә куючының тиешле күрсәтмә актында кабул итүче оешма яисә кабул итүче оешмалар (алга таба бергә - кабул итүче оешма) күрсәтелә, аңарга балалар әтиәниләренең (законлы вәкилләренең) күчерүгә язма ризалыклары нигезендә күчереләчәк.

Үз эшчәнлеге туктатылган очракта, элеккеге оешма әлеге күчерү турында гамәлгә куючының элеккеге оешма эшчәнлеген туктату турында күрсәтмә актын чыгарганнан соң биш эш көне эчендә ата-аналарга (законлы вәкилләргә) язма рәвештә хәбәр итәргә, шулай ук әлеге хәбәрнамәне Интернет челтәрендә үзенең рәсми сайтында урнаштырырга тиеш. Әлеге хәбәрнамәдә бала ата-анасының

(законлы вәкилләренең) тәрбияләнүчеләрне кабул итүче оешмага күчерүгә язма ризалыгы бирү сроклары булырга тиеш.

Баланы күчерү зарурлыгын китереп чыгарган сәбәп турында элеккеге оешма гамәлгә куючыга, ата-аналарга (законлы вәкилләргә) язма рәвештә хәбәр итәргә, шулай ук әлеге хәбәрнамәне Интернет челтәрендә үзенең рәсми сайтында урнаштырырга бурычлы:

лицензия юкка чыгарылган очракта - суд карары законлы көченә кергәннән соң биш эш көне эчендә;

лицензиянең гамәлдә булуы туктатып торылган очракта - мәгариф өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы яки мәгариф өлкәсендә Россия Федерациясе тарафыннан тапшырылган вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимият органы тарафыннан кабул ителгән лицензиянең гамәлдә булуын туктатып тору турында карар турында мәгълүматны үз эченә алган белешмәләрне Лицензияләр реестрына керткән көннән биш эш көне эчендә.

Гамәлгә куючы (гамәлгә куючы вәкаләт биргән орган), әлеге пунктның 1 бүлегендә күрсәтелгән очрактан тыш, тәрбияләнүчеләрнең яшь категориясе, төркем юнәлеше һәм алар тарафыннан үзләштерелә торган мәктәпкәчә белем бирү программалары күрсәтелгән исемлек составы турында элеккеге оешмадан алдан алынган мәгълүматтан файдаланып, кабул итүче оешманы сайлап алуны гамәлгә ашыра.

Гамәлгә куючы (гамәлгә куючы вәкаләт биргән орган) үзе сайлап алган мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларны, тәрбияләнүчеләрне аларга күчерү мөмкинлеге турында сората.

Элеккеге оешма ата-аналарга (законлы вәкилләргә) гамәлгә куючыдан (гамәлгә куючы вәкаләт биргән орган) алган элеккеге оешмадан укучыларны күчерүгә ризалык биргән мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы оешмалар турында, шулай ук балаларның ата-аналарыннан (законлы вәкилләреннән) кабул итүче оешмага күчерүгә язма ризалык бирү сроклары турында мәгълүматны җиткерә. Әлеге мәгълүмат аны алганнан соң ун эш көне эчендә җиткерелә һәм кабул итүче оешманың исеме, мәктәпкәчә белем бирүнең гамәлгә ашырыла торган мәгариф программалары исемлеге, тәрбияләнүчеләрнең яшь категориясе, төркемнең юнәлеше, буш урыннар санын үз эченә ала.

Күчерү турында ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) язма ризалыгын алганнан соң, баланы элекке оешмадан чыгару автомат рәвештә башкарыла.

Тәкъдим ителгән кабул итүче оешмага күчерүдән баш тарткан очракта, баланың ата-аналары (законлы вәкилләре) бу хакта язма гаризада күрсәтә.

Элеккеге оешма кабул итүче оешмага тәрбияләнүчеләрнең исемлек составын, ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) язма ризалыгын, шәхси эшләрен тапшыра.

Тәкъдим ителгән документлар нигезендә. кабул итүче оешма тәрбияләнүчеләрнең ата-аналары (законлы вәкилләре) белән шартнамә төзи һәм шартнамә төзегәннән соң өч эш көне дәвамында, элеккеге оешма эшчәнлеге туктатылуга, лицензияне гамәлдән чыгаруга, лицензиянең гамәлдә булуын

туктатып торуга бәйле рәвештә, күчерү тәртибендә баланы кабул итү турында күрсәтмә акты чыгара.

Кабул итү турындагы күрсәтмә актында күчерелгәнгә кадәр ул белем алган элекке оешманы, баланың яшь категориясен һәм төркем юнәлешләрен күрсәтеп, баланы күчерү тәртибендә кабул итү турында язма ясала.

Кабул итү оешмасында тапшырылган баланың шәхси эше нигезендә, шул исәптән тәрбияләнүчеләр ата-аналарының (законлы вәкилләренең) тиешле язма ризалыгы буенча күчерү тәртибендә кабул итү турындагы күрсәтмә акттан өземтәне үз эченә алган яңа шәхси эшләр формалаша.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.Р. Фәретдиновка йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль районының
Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы,
җитәкче урынбасары Л.Р. Юнысов